**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# 2015 елны Татарстан Республикасында Парклар һәм скверлар елы дип игълан итү турында

Территорияләрне комплекслы үстерү, төзекләндерү, аларда агачлар, үсемлекләр утырту һәм халыкка уңайлы шартлар тудыру мәсьәләләренә җәмгыятьнең игътибарын җәлеп итү максатларында **карар бирәм**:

1. 2015 елны Татарстан Республикасында Парклар һәм скверлар елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:
бер ай эчендә Татарстан Республикасында Парклар һәм скверлар елын уздыру буенча оештыру комитетын төзергә һәм аның составын расларга;
өч ай эчендә Татарстан Республикасында Парклар һәм скверлар елын уздыру буенча төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Парклар һәм скверлар елы кысаларында чаралар уздыру буенча эшне оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Парклар һәм скверлар елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционер җәмгыятенә, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Парклар һәм скверлар елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БУЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2014 ел, 04 сентябрь
№ ПУ-837